Проект

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Шәһәр Советы

КАРАР

_______________ ел №______

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план
чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2020 елның 11 августындагы 41/5 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмә нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проектын һәм 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен караганнан соң,

Шәһәр Советы

К А Р А Р Б И Р Д Е:

1. Расларга:

1) 2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының (алга таба – шәһәр бюджеты) төп характеристикаларын:

- шәһәр бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 18 284 049,47 мең сум итеп;

- шәһәр бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 18 284 049,47 мең сум итеп;

- шәһәр бюджеты кытлыгын (профицитын) 0,0 мең сум итеп;

2) 2026 һәм 2027 елларга шәһәр бюджетының төп характеристикаларын:

- шәһәр бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2026 елга 19 532 556,94 мең сум һәм 2027 елга 20 858 150,18 мең сум итеп;

- шәһәр бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2026 елга 19 532 556,94 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар күләмен 307 859,29 мең сум һәм 2027 елга 20 858 150,18 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар күләмен 650 350,43 мең сум итеп;

- 2026 һәм 2027 елларга шәһәр бюджеты кытлыгын (профицитын) 0,0 мең сум итеп.

2. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 1 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

3. 2026 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиген ноль зурлыгында, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген ноль зурлыгында билгеләргә.

4. 2027 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиген ноль зурлыгында, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген ноль зурлыгында билгеләргә.

5. 2028 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиген ноль зурлыгында, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген ноль зурлыгында билгеләргә.

6. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмен 2 нче кушымтада каралганча шәһәр бюджетында исәпкә алырга.

7. Шәһәр бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлек һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгым төрләре буенча бюджет ассигнованиеләре бүленешен расларга:

1) 2025 елга 3 нче кушымтада каралганча;

2) 2026 һәм 2027 елларга 4 нче кушымтада каралганча.

8. Шәһәр бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

1) 2025 елга 5 нче кушымтада каралганча;

2) 2026 һәм 2027 елларга 6 нчы кушымтада каралганча.

9. Ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2025 елга 84 692,96 мең сум, 2026 елга 88 019,36 мең сум һәм 2027 елга 91 478,86 мең сум итеп расларга.

10. Шәһәр бюджетында субвенцияләрне исәпкә алырга:

1) 2025 елга 5 808 328,07 мең сум күләмендә, шул исәптән:

- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен субвенцияләрне 3 890 695,10 мең сум күләмендә;

- мәктәпкәчә белем белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен субвенцияләрне 1 618 754,90 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 21 003,50 мең сум, шул исәптән методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүгә 20 351,20 мең сум һәм идарә чыгымнарын гамәлгә ашыруга 652,30 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча

укучыларны тукландыруны тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 82 149,50 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 7 087,70 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан административ комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 1 335,00 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 652,30 мең сум күләмендә;

- халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 1 172,70 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 317,70 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаган затларга һәм суд тарафыннан хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 12 341,50 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзелеше өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 4 084,50 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 0,97 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау буенча чаралар үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 13 183,80 мең сум күләмендә, шул исәптән түләмә авырулы терлекләр каберлеген һәм биотермик чокырларны карауга 35,80 мең сум күләмендә һәм хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыруга 13 148,00 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан йогышлы авырулар тудыручы чыганакларда, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм биналарда лаборатор

тикшерү методларын кулланып үткәрелә торган дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне гамәлгә ашыруны оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 10 698,60 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь, наркотик яки башка агулы матдә кулланудан исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 6 592,90 мең сум күләмендә;

- гражданнарның аерым категорияләре өчен шәһәр территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 48 233,80 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алучы гаиләгә бирелгән балаларны тәэмин итү өчен айлык акчалата түләүләрне, һәм үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә тиешле түләүләрне билгеләүгә һәм түләүгә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне 90 023,60 мең сум күләмендә;

2) 2026 елга 6 356 200,94 мең сум күләмендә һәм 2027 елга 6 960 373,38 мең сум күләмендә, шул исәптән:

- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен субвенцияләрне:

2026 елга 4 266 753,70 мең сум күләмендә;

2027 елга 4 680 418,10 мең сум күләмендә;

- мәктәпкәчә белем белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен субвенцияләрне:

2026 елга 1 780 630,40 мең сум күләмендә;

2027 елга 1 958 693,40 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 23 010,90 мең сум, шул исәптән методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүгә 22 326,60 мең сум һәм идарә чыгымнарын гамәлгә ашыруга 684,30 мең сум күләмендә;

2027 елга 25 211,30 мең сум, шул исәптән методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүгә 24 493,40 сум һәм идарә чыгымнарын гамәлгә ашыруга 717,90 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны тукландыруны тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын

күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 84 741,60 мең сум күләмендә;

2027 елга 89 427,30 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 7 432,80 мең сум күләмендә;

2027 елга 7 792,10 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан административ комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 1 399,10 мең сум күләмендә;

2027 елга 1 466,30 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 684,30 мең сум күләмендә;

2027 елга 717,90 мең сум күләмендә;

- халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 1 231,30 мең сум күләмендә;

2027 елга 1 292,90 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 317,70 мең сум күләмендә;

2027 елга 317,70 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаган затларга һәм суд тарафыннан хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 12 946,80 мең сум күләмендә;

2027 елга 13 582,40 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзелеше өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 4 284,20 мең сум күләмендә;

2027 елга 4 494 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү

буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 1,04 мең сум күләмендә;

2027 елга 1,08 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау буенча чаралар үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 13 183,80 мең сум күләмендә, шул исәптән түләмә авырулы терлекләр каберлеген һәм биотермик чокырларны карауга 35,80 мең сум күләмендә һәм хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыруга 13 148,00 мең сум күләмендә;

2027 елга 13 183,80 мең сум күләмендә, шул исәптән түләмә авырулы терлекләр каберлеген һәм биотермик чокырларны карауга 35,80 мең сум күләмендә һәм хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыруга 13 148,00 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан йогышлы авырулар тудыручы чыганакларда, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм биналарда лаборатор тикшерү методларын кулланып үткәрелә торган дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне гамәлгә ашыруны оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 11 105,70 мең сум күләмендә;

2027 елга 11 531,20 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь, наркотик яки башка агулы матдә куллланудан исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 6 619,30 мең сум күләмендә;

2027 елга 6 640,60 мең сум күләмендә;

- гражданнарның аерым категорияләре өчен шәһәр территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 48 233,80 мең сум күләмендә;

2027 елга 48 233,80 мең сум күләмендә;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алучы гаиләгә бирелгән балаларны тәэмин итү өчен айлык акчалата түләүләрне, һәм үз вазыйфаларын түләүле рәвештә башкаручы опекуннарга яки попечительләргә тиешле түләүләрне билгеләүгә һәм түләүгә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне:

2026 елга 93 624,50 мең сум күләмендә;

2027 елга 97 369,50 мең сум күләмендә;

11. Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга:

1) 2025 елга 66 655,40 мең сум күләмендә;

2) 2026 елга 68 708,60 мең сум күләмендә;

3) 2027 елга 71 456,90 мең сум күләмендә.

12. Муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны тотуны, карауны һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән субсидияләрне шәһәр бюджетында исәпкә алырга:

1) 2025 елга 2 149 330,70 мең сум күләмендә;

2) 2026 елга 2 283 503,00 мең сум күләмендә;

3) 2027 елга 2 422 120,20 мең сум күләмендә.

13. Каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән субсидияләрне шәһәр бюджетында исәпкә алырга:

1) 2025 елга 161 349,90 мең сум күләмендә;

2) 2026 елга 169 347,40 мең сум күләмендә;

3) 2027 елга 178 691,90 мең сум күләмендә.

14. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә шәһәр бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләрнең күләме:

1) 2025 елга 4 630,40 мең сум;

2) 2026 елга 11 008,30 мең сум;

3) 2027 елга 10 080,90 мең сум тәшкил итә.

15. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарын 2025 елда, 2026 һәм 2027 еллар план чорында, җирле үзидарә органнарына, муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр яки вәкаләтләр бирү сәбәпле мондый карарлар кабул итү очракларыннан тыш, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз дип билгеләргә.

16. Юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, түбәндәге очракларда бирелә дип билгеләргә:

1) муниципаль-шәхси партнерлык турында төзелгән килешү кысаларында объект төзү һәм (яки) реконструкцияләү;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр рәвешендә, шул исәптән конкурс нигезендә бирелә торган грантлар бирү;

3) акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә карый торган юридик затлар милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салулар һәм (яки) Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый юридик затларның устав капиталларын алга таба арттырып, алар тарафыннан күчемсез милек объектлары сатып алынган очракта;

4) Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен шәһәр һәм (яки) шәһәр яны элемтәсендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле рәвештә керемнәр алынып бетмәү һәм (яки) чыгымнар финанс тәэмин ителү (кайтарылу);

5) даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә керемнәр алынып бетмәү.

17. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Яр Чаллы шәһәре территориаль бүлеге, төзелгән килешүләр нигезендә, шәһәр бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкаралар.

18. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.26 статьясы нигезендә билгеләнгән шәһәр бюждеты акчаларына карата казначылык операцияләре гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.26 статьясы нигезендә билгеләнгән бюждет акчаларына казначылык операцияләрен гамәлгә ашыру тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

19. 2025 елда, 2026 һәм 2027 еллар план чорында шәһәр бюджетына муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль казна предприятиеләре табышының салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләрне керткәннән соң кала торган өлешен күчерү 2024 елда, 2025 һәм 2026 елларда алынган чиста табышның 30 проценты күләмендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1) 2024 ел йомгаклары буенча – 2025 елның 1 сентябренә кадәр;

2) 2025 ел йомгаклары буенча – 2026 елның 1 сентябренә кадәр;

3) 2026 ел йомгаклары буенча – 2027 елның 1 сентябренә кадәр.

20. Йөз процент өлеше (акцияләре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнарында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкилләренә, әлеге хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнары тарафыннан 2024 ел нәтиҗәләре буенча чиста табышны һәм дивидендлар түләүне бүлү мәсьәләләре буенча карарлар кабул иткәндә, 2025 елның 1 сентябренә кадәр срокта (әгәр җәмгыять уставы тарафыннан башка срок билгеләнмәсә) еллык нәтиҗәләр буенча чиста табышның 30 проценты күләмендә акчалата табыш (акцияләр буенча дивидендлар) формасында түләү өчен тавыш бирергә дип билгеләргә.

21. Татарстан Республикасы хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, мәҗбүри таләпләрне бозулар

нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозулар нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны ирекле рәвештә каплаганда түләнә торган түләүләрдән шәһәр бюджетына күчерелгән салым булмаган керемнәр, әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауга һәм бәяләүгә һәм (яки) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү буенча эшләрне оештыруга, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яки) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан рациональ файдалану һәм торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чараларга юнәлдерүне билгеләргә.

22. Торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү, шулай ук санаторий-курортта дәвалану өчен юллама бәясен түләү өлешендә, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында муниципаль хокукый актның гамәлдә булуын 2026 елның 1 гыйнварына кадәр туктатырга.

23. Әлеге Карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

24. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев